| | |
|---|---|
| ГЛАВА ИЛЯКСАЗСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ИЛЕКСАЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

3 ноябрь 2023 ел № 5

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Игәнә-Баш авылы өлешендә 2024 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Игәнә-Баш авылы, Совет урамы, 16 а йорты адресы буенча урнашкан ФАП бинасында 2023 нче елның 15 ноябренә 13 сәгатьтә Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлегенең Игәнә-Баш авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләп кую.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: I нче группа инвалидлар, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнар, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан кала, Илексаз авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2024 елда үзара салымны 300 сум күләмендә кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итәргә тотарга Сез ризамы:

1 Игәнә-Баш авылында "Беларус 82.1" тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүче хезмәте өчен түләү);

2) Игәнә-Баш авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (материаллар сатып алу);

3) Игәнә-Баш авылындагы җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (шофер хезмәтенә түләү);

4) янгын куркынычсызлыгы өчен җиһазлар сатып алу (мотопомпа өчен запас частьләр сатып алу);

5) юл кырыен кисү (ягулык-майлау материаллары сатып алу, йөртүче хезмәтенә түләү);

6)Игәнә-Баш авылы һәйкәлләрен ремонтлау (материаллар сатып алу).

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Илексаз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында, http://sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районы

Илексаз авыл җирлеге башлыгы: Гыйльфанов Ф. М.